ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ БЕРЛЕГЕ

# «МИРАС ЮЛЫ» ПРОГРАММАСЫ

ШКОЛА Казан

## «МИРАС ЮЛЫ» ПРОГРАММАСЫ

Тормыш ул берсеннән-берсе кызыклырак вакыйгалардан һәм мажаралардан тора. Аның эчендә кайнаганда гына тирә-юньдәге кешеләрне, табигатьне, аның серләрен аңларга мөмкин. Урман яңгыры исе белән ләззәтләнү, таң атканда кошлар сайравын тыңлау, жир жиләге белән сыйлану, озаклап велосипедта йөргәннән соң, яисә байдаркада йөзгәннән соң елга буенда ял итеп утыру, поход учагында пешкән ризыктан авыз итү... Боларны аңлатып бирү мөмкинме соң?

Кызыктырамы? Варис булгач, син боларга гына түгел, тагы бик күп нәрсәләрне күрергә ирешерсең әле. Сәяхәткә чыгарсың, табигатькә зарар китермичә, законнарын бозмыйча аның тормышын күзәтерсең; звенонда, отрядында ышанычлы дуслар табарсың, вакытның кадерен белергә өйрәнерсең.

Варислар күп беләләр һәм күп эшлиләр. Мәсәлән, табигатьтә ориентлаша, чатыр кора, учак тергезә алалар, яңгырлы көнне коры калу, "диңгез төене"н бәйләү һәм чишү серләрен беләләр, карта һәм компас белән дөрес, төгәл эш итәләр һ.б.

Варис булгач, син үзең белгәннәрне башкаларга да өйрәтә аласың. Чөнки бездә һәр варис башкаларга да ярдәм итә. Син дә теләсә кайсы вакытта ярдәмгә әзер булырга тиешсең. Кешеләр сиңа таянырга мөмкин икәнлеген белсеннәр. "Әзер бул!" дигән девизыбыз үзең һәм мохтажлар турында кайгыртырга әзер булуың турында сөйли. "Һәр көнне игелекле эш башкарырга!" — дигән шигарьөндәмә гаиләңә, дусларыңа, җәмгыятькә файдалы булуыңны раслый. Синең көн саен кылган яхшы эшең башкаларның тормышын күркәмрәк итә.

Варис буларак, син физик яктан көчле, акыллы һәм намуслы кеше, чын гражданин булырга тиеш. Безнең Берлек сиңа шундый булырга ярдәм итәр.

Я, ничек соң? Безгә кушылырга телисеңме? Әгәр теләгең бар икән, бу программа сиңа яшь варис булу өчен нәрсә эшләргә кирәклеген аңлатыр. Барысы да синең кулыңда!

Димәк,

## ВАРИСЛАР КЕМНӘР СОҢ АЛАР?

Бу сорауга болай дип җавап бирергә була: алар — юлда, хәрәкәттә, эзләнүдә; алар үзләре өчен яңа дөнья ачучылар; кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнүчеләр; алар — күп нәрсә белән кызыксынучылар, тирә-якны нык күзәтүчеләр. Варис тирә-юньне өйрәнеп, анда үз урынын эзли. Ул — яшь разведчик, туган як табигате серләрен, аның җир асты байлыкларын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүче, тикшерүче. Ул — үзеннән алдагы буыннарның бар байлыгын, туган җирен, телен, гореф-гадәтләрен һәм республикада яшәүче башка халыкларның милли традицияләрен мирас итеп алучы яшь гражданин.



## НИЧЕК ВАРИС БУЛЫРГА?

Бу бик гади эш. Беренчедән, сиңа 10 яшь тулу шарт. Икенчедән, син мәктәбегездә варислар отрядының әгъзасы булырга тиеш. Әгәр мәктәбегездә андый отряд булмаса, вожатый һәм дусларың белән үз отрядыңны оештырып кара. Һәм, өченчедән, безнең Берлеккә керергә тиеш булган шартларны төгәл үтәү, өлкән балалар — варислар һәм вожатый-тәрбияче сине законнар, традицияләр, символлар һәм аеру билгеләре белән таныштыра һәм галстук бәйләргә өйрәтә. Аннан соң әти-әниең, яисә опекуның (тәрбиячең) белән килешеп, әгъзалык гаризасы тутырырга кирәк булыр. Отряд сборында кабул ителгәннән соң, вариска шәхси китапчык бирелә. Анда лагерьларда, сәяхәтләрдә ирешкән уңышлар, алган бүләкләр һ.б. язылып бара.





## ВАРИСЛАРНЫҢ ТАНТАНАЛЫ ВӘГЪДӘСЕ

Мин, _____________, үзем теләп Татарстан варислары Берлегенә керәм, варисларның законын һәрвакыт төгәл үтәргә сүз бирәм.

## ВАРИСЛАРНЫҢ ЗАКОНЫ ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Варислар берлеге әгъзаларының законнары һәм традицияләре — алар үз-үзеңне тоту кагыйдәләре ул. Аларны һәркем үтәргә тиеш.

## ГРАЖДАНЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

**Варисларның беренче законы болай куша**: “*Варис үз республикасына булыша, аның лаеклы гражданины булырга тырыша*”. Ничә яшьтә булуына карамастан варис күптөрле эшләр башкара: табигатьне саклый һәм яклый, өлкәннәргә һәм ярдәмгә мохтаҗларга булыша, халыкның милли гореф-гадәтләрен саклый, республикабыздагы төрле милләт халыклары арасындагы дуслыкны ныгыта. Болар — үзең өчен, башка кешеләр өчен, безнең җәмгыять һәм республикабыз өчен, гомумән, файдалы зур һәм кечкенә эшләр.

## ДӨРЕСЛЕК ТРАДИЦИЯСЕ

**Варисларның икенче законы болай куша**: “*Варис дөреслек, хаклык өчен кыю тора*”.

Һәр кеше тугач та зур байлыкка ия: аның яшәүгә, азатлыкка һәм бәхеткә омтылырга хакы бар. Ләкин тормышта үз хокукыңны яулап алу җиңел түгел. Аның өчен көрәшергә кирәк. Варис һәрвакыт дөресен сөйли, намуслы булып кала.

## ИГЕЛЕКЛЕЛЕК ТРАДИЦИЯСЕ

**Варисларның өченче законы**: “*Варис— тугрылыклы иптәш, олыларга һәм кечеләргә булыша, беркемне дә авырлыкларда ялгыз калдырмый*”, — дип өйрәтә. Ягымлы сүз дөньяны яктырак һәм шәфкатьлерәк итә. Мәрхәмәтле эшләр ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә кирәк ул. Әгәр башкаларның сиңа мөнәсәбәте яхшы булуын теләсәң, үзең дә аларга карата рәхимле бул! Шуңа күрә варислар авыруларга, гариплләргә, ялгыз картларга һәм ярдәмгә мохтаҗ сабыйларга һәрвакытта да ярдәм кулы сузалар.

## ҮСЕШ ТРАДИЦИЯСЕ

**Варисларның дүртенче законы**: "*Варис күп белергә, көчле һәм җитез булырга омтыла*", — дип өйрәтә. Берлек таләпләрен үтәү, куелган максатка ирешү җиңел түгел. Моның өчен катлаулы сынаулар үтәргә, яңа үрләр яуларга кирәк. Сәяхәтләргә чыгарга, кешеләргә ярдәм күрсәтергә, индеецлар булып уйнарга, сәясәтне аңларга өйрәнерсең. Монда, әлбәттә, сиңа әлеге закон ярдәм итәр.

## МИРАС ТРАДИЦИЯСЕ

**Варисларның бишенче законы**: "*Варис табигатьне, туган ягының мәдәниятен уяу саклый*", — дип өйрәтә.

Тирә-юньдәге һәммә нәрсә табигатьнең миллион еллык үсеше, кешенең меңнәрчә еллык хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән бу байлык буыннан-буынга мирас булып күчкән. Төсләр матурлыгына, күз чагылдыргыч яшеллеккә игътибар ит, тормыш шавын тыңлап кара. Табигать кешегә гүзәллек һәм шатлык бүләк итә. Вакытлар узу белән бу зур байлык сиңа мирас булып калачак. Аны киләчәк буыннар өчен ничек саклап калырга соң? "Тарихы булмаган халыкның киләчәге юк", — ди халык. Шуңа күрә тарихны өйрәнергә, халыкның гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә, ата-бабаларның телен белергә кирәк.

## ВАРИСЛАРНЫҢ ДЕВИЗЫ

**Варисларның девизы** — "*Һәрвакыт әзер!*" Варислар өлкәннәр тормышына әзерләнеп кенә калмыйлар, ә бүген дә актив тормыш алып баралар. Варис мохтаҗ кешеләргә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Шуңа күрә варислар тормышта барган вакыйганы аңларга, теләсә кайсы авырлыкка да әзер булырга тиеш.

## ВАРИСЛАРНЫҢ ШИГАРЕ (ӨНДӘМӘСЕ)

**Татарстан варисларының шигаре** — "*Көн саен яхшылык кыл!*" Варислар ярдәмгә мохтаҗ туганнарына, якыннарына, дусларына һәм таныш булмаган кешеләргә дә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торалар. Тыныч кына, мактанмыйча һәм мактау көтмичә эшләнгән һәр файдалы эш — яхшы. Һәр игелекле эштән соң безнең тормышыбыз бәхетлерәк була бара. Көн дә яхшылык кылу һәр варис өчен гадәти хәл, көндәлек яшәү рәвеше.



## БЕЗНЕҢ СИМВОЛЛАР

Куелган максатка ирешү һәм көчебезне юк-барга сарыф итмәс өчен, без үзебезнең символларыбызны кабул иттек. Аларның төсе: зәңгәр, яшел, кызыл. Бу символларны син байракта да, отряд флагында да, галстугында да, значокта да, форманың аеру билгеләрендә дә, җиңнә тегелгән билгеләрдә дә күрәсең. Ә һәр төс нәрсәнедер аңлата:

- зәңгәр — безгә дөрес юлны күрсәтүче төс. Сәяхәттә генә түгел, тормышта да дөрес юнәлеш сайлый белү, юлдан читкә тайпылмау кирәк;
- яшел — безнең Җир шарыбыз төсе. Аның биш кисәгендә дә кешеләр, диннәре, милләтләре, инанганлыклары нинди булуга карамастан, тыныч һәм бәхетле яшәргә телиләр;
- кызыл — игелеклелек төсе ул, кешеләргә игелек кылучы, аларга үз җанының җылысын өләшүче булган күңелнең бер чаткысы.

## СИНЕҢ ЗВЕНОҢ



Звено — республикабызның иң алдынгы балалар төркеме. Нәкъ шундый звено белән көчле инде ул безнең оешмабыз. Ул звенога ихтыяҗлары бердәм, үзара дус һәм тату, яшәү урыннары бер-берсенә якын булган 6-9 бала берләшә.

Звено — коллектив ул. Аның көче бердәмлектә. Аның барлык әгъзалары вакытларын кызыклы һәм файдалы итеп уздыра беләләр. Монда балалар бер уй белән яшәүнең, бергәләшеп походларга чыгуның, төрле уеннар белән шөгыльләнүнең, Берлек йөкләмәләрен үтәүнең никадәр мавыктыргыч икәнлегенә ышаналар. Алдынгы звено күпчелек эшләрен саф һавада башкара. Үзенең балигъ булган отряд вожатые (18 яшь), класс җитәкчесе яки звено әгъзаларының ата-аналары җитәкчелегендә сәяхәткә чыга. Сәяхәтләр — звено тормышында иң кызыклы эшләрнең берсе. Нәкъ менә учак янында инде һәр варис безнең оешмабызның чын рухын аңлый.

Һәр звено исемне үзе сайлап ала. Хайваннар, кошлар, китап, кинофильм геройларының, атаклы каһарманнарның исемнәрен алырга да мөмкин.

Звенонын үз эмблемасы сурәтләнгән флагы булырга мөмкин. Звено әгъзалары үзләре уйлап тапкан һәм ясаган флаг тагын да яхшырак. Звено үз флагын кадерләп тота, әһәмиятле эшләр үтәргә барганда аны үзе белән ала.

Звенонын максаты — сине һәм дусларынны шәп сәяхәтчеләр, көчле, белемле, тәрбияле, варисларнын законнарына һәм традицияләренә тугрылыклы кешеләр итеп тәрбияләү.

## ЗВЕНО ҖИТӘКЧЕСЕ

Звенонын үз җитәкчесе була. Җитәкче итеп варислар үзләре хөрмәт иткән, звено мәнфәгатьләре өчен көрәшергә көче һәм теләге булган кешене сайлыйлар. Ул звено эшендә зур роль уйный. Һәр эштә: сәяхәттә, сборда звено әгъзаларын үз артыннан ияртә, барлык варисларны да звено тормышында катнаша алырлык эш белән тәэмин итә. Матур итеп яза белүчене — елъязмачы, төгәл санаучыны — хисапчы (казначей) булырга өйрәтә. Әгәр звенонын үз палаткалары һәм башка кирәк-ярак җиһазлары булса, звено җитәкчесе квартирмейстер билгели. Шулай ук ул завхоз, элемтәче, пешекче, хәтта курчаклар белән спектакль кую өчен режиссер вазифаларын билгеләргә мөмкин.

Чирек саен сайлау юлы белән һәр вариска звено җитәкчесе булу мөмкинлеге бирелә.



*Звено җитәкчесенең бурычы* — балаларны файдалы эшләр белән кызыксындырып, коллектив тормышы белән мавыктыра алу. Безнең Берлек "**Бер кеше — бөтенебез өчен, бөтенебез — бер кеше өчен!**" — дигән идея белән яши.



## ЗВЕНО ЭШЧӘНЛЕГЕ

Алдынгы звено һәрнәрсәне мөстәкыйль эшли. Ул экскурсияләр оештыра, үзенең почмагын яисә штабын булдыра, төрле игелекле эшләр башкара. Звено даими төстә үзенең штабында яисә кайсы да булса әгъзаның өендә (әти-әниләрнең рөхсәте белән) үз сборын, ягъни җыенын үткәрә. **Сбор** — ул балалар үзидарәсенең иң югары органы. Анда варислар коллектив тормышы өчен иң мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр, уй-фикерләрен җиткерәләр, карар кабул итәләр.

Сборларда звено әгъзалары яңа күнекмәләр үзләштерәләр (мәсәлән, учак тергезергә, беренче медицина ярдәме күрсәтергә, "диңгез төеннәре" ясарга өйрәнәләр), игътибарны, хәтерне, зиһенне яхшырта торган уеннар белән шөгыльләнәләр.

Варислар сборларын үзләре үткәрәләр. Беренче көннәрдә, коллектив формалашкан вакытта сборны вожатый-остаз уздыра. Аннан балалар ияләшкәч, вожатый-остаз, я звено җитәкчесе кушуы белән һәр звено сборларны үзе үткәрә.

Сборның программасын төзү җиңел түгел, аның өчен күп өйрәнергә, күп белергә кирәк. Барысы да алдан уйланылган, әзерләнгән программа буенча сбор үткәрү авыр эш түгел.

Звенонын һәр әгъзасы бу эшне булдыра ала. Беренче чиратта сборның кайда, кайчан булачагын төгәл сөйләшергә кирәк. Әгәр, берәрсе сборның кайда үтәсен белми калып, озак эзләсә, соңга калса, бу бик начар күренеш. Төгәллек — варисның яхшы сыйфаты.




## СИНЕҢ ОТРЯДЫҢ

Теләсә кайсы варис звено әгъзасы гына түгел, ул әле коллективның — отрядның әгъзасы да булып исәпләнә. Чөнки звено отрядның бер кисәге. Кагыйдә буларак, отрядта 3-4 һәм аннан да күбрәк звено булырга мөмкин. Һәр варис үзенең отряды белән исәпләшә, ана лаек булып яшәргә тырыша. Отряд эшендә барысы

да кызык: күңелле сборлар, мавыктыргыч сәяхәтләр, учак янында җырлар, спорт ярышлары, тимурчылык десантлары һ.б. Ә кечкенә дусларыгыз өчен сезнең отрядта этабарлар чылбыры оештырып була. Алар белән бергәләп сәяхәткә чыгарсыз, төрле уеннар уйнарсыз, вожатый-остаз биргән биремнәрне үтәрсез.

Отрядның тасмага исеме язылган байрагы, билгесе һәм галстугы бар.

Сбор — отрядның иң мөһим, традицион эше булып санала. Анда варисларның звенолары коллектив тормышындагы төрле мәсьәләләрне хәл итәләр, отряд советы сайлылар, звенолар арасында ярыш үткәрәләр, булачак бәйрәмнәргә, сәяхәтләргә, очрашуларга әзерләнәләр.

Отряд — гомумән зур көч ул, аның белән җитди эшләр башкарып чыгарга мөмкин.

Отрядның остазы һәм оештыручысы кем?

Отрядның остазы һәм оештыручысы — отряд вожатые. Ул яше белән дә өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк тә, аның махсус әзерлеге дә бар. Варис булу өчен кирәк булган бар нәрсәне сиңа вожатый өйрәтә ала.

Вожатыйга эшендә отряд советы ярдәм итә. Отряд советына барлык звено җитәкчеләре сайлана. Отряд советы белән сборда сайланган рәис җитәкчелек итә. Димәк, сине отряд рәисе итеп сайлаган варислар сиңа әйдәп баручы буларак ышаналар. Син аларның ышанычларын аклап, һәрчак, һәр җирдә активлык һәм инициатива күрсәтергә, коллектив өчен мөһим булган кызыклы эшләр оештырырга тиешсең.

## ЭШНЕ НИЧЕК ПЛАНЛАШТЫРЫРГА?

Планлаштыру — мавыктыргыч эш. Ул коллективка пөхтә итеп язып, отряд почмагына элеп кую өчен генә түгел, ә үткән һәм булачак игелекле һәм файдалы эшләрне бергәләп анализлау өчен дә кирәк. Эшләгән эш кайчан кызыклы була соң? Билгеле, варис үзе теләп башкарса гына. Биредә ориентир булып дүрт "үзебез" кагыйдәсе исәпкә алынырга тиеш:

- үзебез планлаштырабыз;
- үзебез оештырабыз;
- үзебез үткәрәбез;
- үзебез йомгак ясыйбыз.

Бу очракта һәркемгә эш табыла. Звено һәм отряд тормышы вожатыйларның һәм варисларның үзләренең нинди булуларына



бәйле. Тәҗрибә күрсәткәнчә, планны коллективның традицияләре нигезендә чирек саен төзү уңайлы.

Варис эшләрен башлаганда дөрес юнәлеш алу өчен биш почмаклы йолдызчыктан файдаланырга мөмкин. Йолдызчыкның нурлары эш юнәлешләрен күрсәтә.




**Хезмәт** — файдалы эшләр башкару һәм укуда бер-береңә ярдәмләшү ул.

**Тынычлык** —әйләнә-тирә мохит турында кайгырту, туган якны өйрәнү, теләктәшлек ярминкәләре, тынычлык турында җыр фестивальләре үткәрү.

**Кайгыртучанлык** — шәфкатьлелек, өлкәннәргә һәм кечеләргә булышу, ялгызлар һәм авырулар турында кайгырту. (Кибеткә бару, өй җыештырырга ярдәм итү, хат укып, я хат язып бирү һ.б.).

**Ятышлылык** — күңелле спорт стартлары, зирәкләр һәм тапкырлар клублары, концертлар оештыру, файдалы һәм кызыклы итеп ял итә белү.

**Һөнәрләр** — варислар сборларында сәяхәтләр вакытында һәм көндәлек тормышка кирәкле һөнәрләрне үзләштерү.

Ә отряд тормышын хасил итә торган эшләр чылбыры түбәндәгечә: бергә башкарылачак эшләр турында сөйләшеп, анализлап, өйрәнү өчен отряд вожатыйлары советын үткәрү — 2 сәгать;

Звенолар сборын әзерләү, отряд сборы турында фикер алышу өчен отряд советы үткәрү — 2 сәгать;

Уеннар, дәресләр, һөнәрләр өйрәнү, отряд сборы турында фикер алышу өчен отряд советы үткәрү — 2 сәгать;

Звено ярышлары, күмәк эшләр, булачак бәйрәмнәргә, сәяхәтләргә һәм очрашуларга әзерлек турында сөйләшү өчен отряд сборы үткәрү — 3 сәгать.

Бу чылбыр "Отряд эшендә 9 сәгать" дип атала. Ул сезгә эшегезне дөрес оештырырга ярдәм итәр.

## ВАРИСЛАРНЫҢ БИЕКЛЕКЛӘРЕ

Варисларның “Әзер бул!” дигән девизы урта гасыр каһарманнары заманыннан ук килә. Варис, алар кебек үк, көчен һәм белемен туктаусыз үстерү өстендә эшли, үз бурычын төгәл башкара, кыенлыктан чыгу юлларын белә, кирәк чакта башкаларга ярдәмгә килә.

Варислар биеклеге — синең оешмадагы үсеш программаң һәм осталыгыңны арттыру юлы, өзлексез үз өстеңдә эшләү ул. Теге яки бу биеклектә кирәк булган белемен камилләшкәч, син аны җиңел генә тормышта куллана алырсың. Биеклек шартларын син теләсә кайсы тәртиптә, теләсә кайсы вакытта үти аласың. Бу биеклекләрнең төп кыйммәте — син ирешкән осталык, син ия булган зирәклек, синдәге тәҗрибә. Әнә шулар сине нәкъ менә чын варис итәчәк.

## “ВАРИС” ИСЕМЕНЕҢ 1 БИЕКЛЕГЕ

**Бу биеклекне яуларга әзер булу өчен вариска түбәндәгеләрне эшләү таләп ителә**:

1. Варисларның законнарын, традицияләрен, девизларын, шигарен (өндәмәсен) белү.
2. Үз республикаңның, шәһәреңнең, районыңның тарихын белү өчен өч халык җырын һәм биюен башкару.
3. Үзеңнең звеноң һәм аның флагы турында сөйли белү.
4. Экстремаль шартларда карар кабул итә белү:
   - табиб, милиция, янгын сүндерүчене чакыру;
   - беренче медицина ярдәмен күрсәтү (кечкенә җәрәхәтне юу, бәйләп кую, кулга кергән шырпыны алу, авыруны дөрес итеп күчерү, аңын югалткан кешегә ярдәм итә белү).
5. Бинада һәм урамда өстәл һәм спорт уеннары оештыру, кечкенәләрне уйнату.





6. Хезмәтеңне дөрес итеп оештыру, вазифаларны дөрес бүлү һәм аларның үтәлешен тикшерү.
7. Көннәрне дөрес бүлү.
8. Отрядның яраткан җырларын белү һәм башкару.
9. Кунакта, урамда, транспортта, җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү.
10. Урманда йөри белү. Үләннәрне, үсемлекләрне, агачларны, куакларны, кошларны, җәнлекләрне танып, сурәтләп бирү.
11. Беркөнлек ике сәяхәттә булу:
   - төеннәрнең төп төрләрен белү, аларның ни өчен кирәк икәнлеген аңлату;
   - учакны дөрес тергезә һәм сүндерә белү;
   - сәяхәт өчен кирәкле әйберләрне сайлап ала белү, биштәрне дөрес тутыру;
   - компас белән эш итә белү;
   - картадагы шартлы билгеләрне белү;
   - карда яки юеш җирдә кеше, велосипед, мотоцикл, автомобиль һәм җәнлек яки кош эзен танып белү...



12. Сәяхәттә чакта кирәк булачак куркынычсызлык кагыйдәләрен белү, велосипедта йөрү.
13. Киемеңә ямау салу, үз кулың белән вак-төяк әйбер эшләү, кул белән тегә торган җөйләрне белү.
14. Ризык әзерли, өстәл көйли белү.
15. “Ким” уенында 10 әйберне санап чыгу (истә калдыру вакыты — 1 минут).
16. Иртәнге гимнастика өчен 10 физик күнекмә ясап күрсәтү. Аларны көн саен үтәү.



17. Үзеңнең спорт нәтиҗәләреңне белү (җирдән этелү, турникта тартылу, озынлыкка сикерү, 500 метрга йөгерү).

18. Звено әгъзаларың өчен файдалы эш башкару: кызыклы очрашу, кичә, уен.

19. Теләгән берәр һөнәр сайлап алу.

## "ӨЛКӘН ВАРИС" — II БИЕКЛЕК

**"Өлкән варис"ның II биеклеге өчен түбәндәге эшләр таләп ителә:**

1. Татарстан варислары Берлегенең оештыру төзелешен, "Мирас юлы" программасын белү.

2. Безнең республиканың балалар оешмаларын белү.

3. Звено һәм отряд сборлары үткәрү.

4. Дәүләт байрагын, отряд флагын куллана белү.

5. Республиканың тарихи үсешенең төп этапларын белү. Шәһәрегезнең, районыгызның тарихи урыннарында экскурсияләр үткәрергә әзер булу.

6. Спорт ярышлары, эстафеталар, конкурслар уздыруның кагыйдәләрен белү.

7. Звенода үткәрелгән эшләрне анализлый белү.

8. Табигатьне саклау кагыйдәләрен белү, шуның буенча игелекле эшләр башкару.

9. Йорт хайваннарының һәм кыргый җәнлекләрнең, кошларның эзен белү һәм тану. Сезнең якта яшәүче 10 кыргый (кошкорт, балык, имезүче) җәнлекнең рәсемен ясый белү.





10. Республикабызда үсә торган агач, куак, үсемлек, чәчәкләр төрләрен танып әйтә белү.

11. Алты халык җыры һәм ике бию (берсе халык биюе) башкару.

12. Төп музыкаль һәм театраль жанрларны белү.

13. Үз халкының сәнгатен һәм мәдәниятен белү.

14. Бер төнлек туристик походта катнашу:

- картадагы топографик шартлы билгеләрне аңлый һәм ориентлаша белү;
- карта һәм компас ярдәмендә сәяхәт маршрутын төзү;
- чатыр кую өчен уңайлы урын таба, чатырны дөрес һәм тиз итеп куя, куну өчен йокы җайланмасы әзерли белү.
- урманда яңгырдан ышыклану урыны әзерләү;
- берничә көнгә чатырлы лагерь кую һәм соңыннан эзен калдырмыйча җыеп алу;
- 1-2 шырпы белән учак тергезү һәм аны дөрес итеп сүндерә белү;
- поход шартларында ашарга пешерү өчен урын әзерләү, ике төрле аш әзерли белү, учактагы утны дөрес яндырып тору;
- таныш булмаган җирдә, урманда, походта ориентлаша белү.



15. Беренче медицина ярдәме күрсәтә белү (аңны югалтканда, эссе сукканда, өшегәндә, күп итеп кан югалтканда, азык белән агуланганда, пешкәндә, елан чакканда, кулны сындырганда, сулыш алу туктаганда).

Авыруны күтәреп бару өчен носилка әзерли белү.

16. Звенода һәм отрядта хезмәтне оештыру.

17. Берәр ватылган әйберне төзәтү өчен иң гади иструментлар (эш кораллары), җайланмалар әзерләү.

18. Шәхси гигиена нигезләрен белү.

19. Тәмле ризык әзерләү, экибана, я чәчәк бәйләме ясау, иң гади өс киеме моделен эшләү.

20. "Ким" уенында бер минут эчендә 24 әйбернең 20 сең истә калдыру.

21. Азык-төлекнең бәясен белү, кибеттән әйбер, аптекадан дарулар сатып алу, гаилә бюджетын күз алдына китерү.

22. Үзеңне суда тоту кагыйдәләрен белү, ике төрле стиль белән 50 метр араны йөзеп үтү.



23. Шәфкатьлелек ярминкәсендә, концертында яисә башка эштә катнашып, үз звеноң өчен акча эшләү.

24. Үзең теләгән тагын ике-өч һөнәр сайлап алу.

## "ВАРИС-ИНСТРУКТОР" — III БИЕКЛЕК

**Өченче биеклектә "Варис-Инструктор"дан түбәндәге эшләрне үтәү таләп ителә:**

1. Республика тарихын белү.

2. Иң мөһим халыкара балалар һәм яшьләр оешмалары турында белү.

3. Республикада яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен өйрәнү.

4. Һәр чирек саен звено һәм отряд эшчәнлегенең программасын төзү.

5. Туристик поход яки җәйге чатыр лагере оештыруда катнашу (5 көнлек):

• чатырлы лагерь өчен җайлы урын сайлау, аны планлаштыру, утын әзерләү, балта белән эш итә белү;

• ерым яки елга аркылы чыгу корылмасы әзерләү;

• өч көнлек сәяхәттә кирәк булачак продуктлар исемлеген төзү;



• сәяхәттә иртәнге, төшке һәм кичке ашларны әзерләп, аш пешерү осталыгын күрсәтү. Сәяхәт вакытында кирәк булачак җиһазлар әзерләү;

• туристик төеннәр бәйләү;

• кыр карталарын яхшы итеп уку, андагы шартлы билгеләрне аңлау, картада үзеңнең торган урыныңны билгеләү;

• "күз белән" генә әйбернең ераклыгын һәм биеклеген ачыклау; җилнең юнәлешен билгеләү.

6. Суга батучыны коткару кагыйдәләрен үзләштерү.

7. Ике төрле алым белән 100 метр араны йөзеп узу, су өстендә 1 минут хәрәкәтсез тору.

8. Поход аптечкасында нәрсәләр булганлыгын ачыклау һәм аларны дөрес куллана белү. Ясалма сулыш ясарга өйрәнү.

9. Баш, кул һәм аяк канаганда беренче медицина ярдәме күрсәтеп, бәйләп кую.

10. Йөрәк өянәге вакытында кирәкле ярдәм күрсәтә белү.

11. Хастаханәдә авыруларны карап, ике көн дежур тору.

12. Көнеңне һәм эшеңне дөрес оештыру.

13. Берәр музыка, я матур әдәбият әсәрен сурәтләп бирү.

14. Бәйрәм уздырыла торган бүлмәне бизәү.

15. Тегә белү.

16. Кунаклар кабул итү өчен табын әзерләү.

17. Спорт ярышларында судьялык итү кагыйдәләрен өйрәнү һәм ярышларда судья булу.

18. Урамда һәм бинада спорт уеннары, эстафеталар, конкурслар үткәрү.

19. Төрле чараларның, бәйрәмнәрнең һәм конкурсларның сценарийларын төзи белү.

20. Өч ай буена эзтабарлар чылбырының вожатые булу. Алдан үзләштергән һөнәреңбуенча алар өчен берәр түгәрәк оештыру.

21. Тагын ике һөнәр үзләштерү.

